ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_03.11.2021_ М ө с л и м №_491_

**Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарын гамәлдән чыгару турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРДЕ:**

1. Гамәлдән чыгарырга:

1.1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 21 июлендәге 318 номерлы карарын;

1.2. «Мөслим муниципаль районы территориясендә эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау тәртибен раслау турында» 2016 елның 8 июнендәге 207 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарын.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (http:// muslumovo.tatarstan.ru) һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше башлыгы урынбасары Р.А. Ильясовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Р. Хуҗин**